КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 14 май г.Казань № 331

2021 елга торак урын наемы шартнамәсе нигезендә бирелә торган торак төзелеше буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтүгә субсидияләр күләмен исәпләп чыгару өчен Татарстан Республикасының авыл территорияләрендә торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры кыйммәтен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 14 май, 387 нче карары белән расланган торак урыннар наемы шартнамәләре буенча торак алучы гражданнар исемлекләрен формалаштыру һәм раслау тәртибенең 14 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

2021 елга торак урын наемы шартнамәсе нигезендә бирелә торган торак төзелеше буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтүгә субсидияләр күләмен исәпләп чыгару өчен Татарстан Республикасының авыл территорияләрендә торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры кыйммәтен 42 400,0 сум күләмендә расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин